| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.12.2025 г. Казань № под-2178/25

2025/2026 уку елында «Сәйяр» балалар
һәм яшүсмерләр театрлары республика
фестивален үткәрү турында

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы «Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын үтәү максатында, б о е р а м:

2. «Сәйяр» балалар һәм яшүсмерләр театрлары республика фестивален 2026 елның 12 гыйнварыннан 25 маена кадәр үткәрергә (алга таба – Фестиваль).
3. Түбәндәгеләрне расларга:
- 2025/2026 уку елында «Сәйяр» балалар һәм яшүсмерләр театрлары республика фестивален үткәрү турындагы нигезләмә;
- 2025/2026 уку елында «Сәйяр» балалар һәм яшүсмерләр театрлары республика фестивален оештыру комитеты составы.
4. Милли мәгариф идарәсенә (А.С.Шарипова) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының мәгариф идарәләренә (бүлекләренә) җиткерергә.
5. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г.К.Имамова) Фестивальне оештыру һәм үткәрү чыгымнарын түләргә.
6. Татарстан Республикасының муниципаль мәгарифне идарә итү органнарына гомуми белем бирү оешмалары укучыларының Фестивальдә катнашуын тәэмин итүне, озатучы педагогларны билгеләүне, аларга юлда йөргәндә һәм Фестиваль үткәрү вакытында балаларның тормышы, сәламәтлеге һәм иминлеге өчен җаваплылык йөкләүне тәкъдим итәргә.
7. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары М.З.Закировага йөкләргә.

Министр И.Г.Һадиуллин

Расланды
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2025 елның «25 декабреннән»
под-2178/25
номерлы боерыгы белән

2025/2026 уку елында «Сәйяр» балалар һәм яшүсмерләр театрлары республика фестивален үткәрү турында
НИГЕЗЛӘМӘ

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге «Сәйяр» балалар һәм яшүсмерләр театрлары республика фестивален үткәрү турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Сәйяр» балалар һәм яшүсмерләр театрлары республика фестиваленең (алга таба – Фестиваль) максатын, бурычларын, оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Фестиваль Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы «Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын (алга таба – Дәүләт программасы) тормышка ашыру кысаларында үткәрелә.

II. Фестивальнең максаты һәм бурычлары

2.1. Фестивальнең максаты – балаларда рухи мәдәният, күпмәдәниятле җәмгыять кыйммәтләрен формалаштыру һәм мәдәни мирас традицияләрен саклау.

2.2. Фестивальнең бурычлары:

яшь буынның язучылар һәм драматурглар иҗатын өйрәнүгә мотивациясен арттыру;

укучыларның театр сәнгатенә игътибарын җәлеп итү; балаларны һәм яшьләрне сәнгати-эстетик һәм әхлакый тәрбияләү;

иҗади сәләтле укучыларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү.

III. Фестиваль оештыручылары

3.1. Фестивальне оештыручы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3.2. Фестивальнең уртак оештыручылары:

«К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча);

«Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча);

«ТАТМЕДИА» акционер җәмгыятенең «Сәхнә» һәм «Салават күпере» журналлары редакциясе (килешү буенча).

## IV. Фестивальне үткәрү этаплары

4.1. Фестиваль 3 этапта үткәрелә:

I этап – мәктәп – 2026 елның 30 гыйнварына кадәр;

II этап – муниципаль – 2026 елның 9 февраленнән 27 февраленә кадәр;

III этап – республика – 2 турда үткәрелә:

читтән торып – 2026 елның 6 мартыннан 27 мартына кадәр;

күчмә тур – 2026 елның 15 апреленнән 30 апреленә кадәр.

## V. Фестиваль катнашучылары

5.1. Фестиваль катнашучылары – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларының балалар театр коллективлары, Фестивальнең муниципаль этабы җиңүчеләре һәм призерлары арасыннан.

5.2. Фестиваль түбәндәге яшь категорияләре арасында оештырыла:

мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбияләнүчеләре;

гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучылары;

гомуми белем бирү оешмаларының 5-8 сыйныф укучылары;

гомуми белем бирү оешмаларының 9-11 сыйныф укучылары.

## VI. Оештыру комитеты

6.1. Фестивальне үткәрүне оештыру өчен Фестиваль оештыру комитеты формалаштырыла. Фестивальнең Оештыру комитеты Министрлык вәкилләреннән кимендә алты кеше санында формалаштырыла һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

6.2. Оргкомитет вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Фестивальне үткәрү программасын эшләү, раслау, аның үтәлешен тәэмин итү;

Фестивальнең республика этабы жюрисын формалаштыру һәм аның эшен координацияләү;

Татарстан Республикасы мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарын Фестивальне үткәрү турында мәгълүматландыру;

катнашучыларга Фестивальнең республика этабын үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр итү;

әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән һәр яшь категориясе буенча Татарстан Республикасының һәр муниципаль берәмлегеннән Фестивальнең республика этабы катнашучыларының квотасын билгеләү;

әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән һәр яшь категориясе буенча Фестивальнең республика этабы лауреатларының квотасын билгеләү;

Фестиваль җиңүчеләрен бүләкләү тантанасын оештыру;

Фестивальне оештыру һәм үткәрүгә кагылышлы башка мәсьәләләрне хәл итү.

6.3. Мәктәп этабын үткәрү өчен белем бирү оешмасы тарафыннан Фестивальнең мәктәп этабын оештыру комитеты формалаштырыла.

6.4. Муниципаль этапны үткәрү өчен мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы (муниципаль район, эчке шәһәр районы, эчке шәһәр

бүленешенә ия булмаган шәһәр округы) тарафыннан Фестивальнең муниципаль этабын оештыру комитеты формалаштырыла.

## VII. Фестиваль жюрие

7.1. Мәктәп этабында катнашучыларның чыгышларын бәяләү өчен белем бирү оешмасы тарафыннан Фестивальнең мәктәп этабы жюрие формалаштырыла.

7.2. Муниципаль этап катнашучыларының чыгышларын бәяләү өчен мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы (муниципаль район, эчке шәһәр районы, эчке шәһәр бүленешенә ия булмаган шәһәр округы) тарафыннан Фестивальнең муниципаль этабы жюрие формалаштырыла.

7.3. Фестивальнең республика этабы жюрие (алга таба – Жюри) драма театрлары артистларыннан, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать һәм мәдәният эшлеклеләреннән кимендә биш кеше санында формалаштырыла һәм Министрлык боерыгы белән раслана. Жюри рәистән, сәркатиптән һәм жюри әгъзаларыннан тора.

7.4. Жюри вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Фестивальнең йомгаклау этабының читтән торып һәм күчмә турларында чыгышларны бәяләү;

читтән торып туры катнашучыларының рейтинг исемлеге нигезендә һәм оештыру комитеты билгеләгән квота нигезендә күчмә тур катнашучыларын билгеләү;

Министрлыкка Жюри утырышында рәислек итүче тарафыннан имзаланган Жюри беркетмәсен тапшыру.

7.5. Жюри утырышлары күчмә рәвештә үткәрелә. Жюри утырышы, рәисне дә кертеп, жюри әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 2/3 өлеше катнашса, хокукый дип санала. Жюри карарлары ачык тавыш бирү юлы белән жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, жюри утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

## VIII. Фестивальне үткәрү тәртибе

8.1. Фестивальнең мәктәп һәм муниципаль этапларын үткәрү тәртибе, чыгышларны бәяләү критерийлары, жюри составлары тиешле рәвештә Фестивальнең мәктәп һәм муниципаль этаплары оештыру комитетлары тарафыннан билгеләнә.

8.2. Фестивальнең республика этабында катнашу өчен гаризалар кабул итү 2026 елның 6 мартына кадәр Zulfiya.Zakirzyanova2025@yandex.ru электрон почтасына кабул ителә. Гариза Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының мәгариф идарәләре (бүлекләре) тарафыннан әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтасы үрнәгендә формалаштырыла. Гаризада Фестивальнең муниципаль этабы җиңүчеләренең һәм призерларының чыгыш видеоларына сылтамалар була.

8.3. Фестивальнең республика этабының читтән торып турында катнашучыларның чыгышлары, Жюри тарафыннан, тәкъдим ителгән видеоматериаллар буенча бәяләнә. Читтән торып тур нәтиҗәләре буенча Жюри тарафыннан читтән торып тур катнашучыларының рейтинг исемлеге формалаштырыла.

8.4. Фестивальнең республика этабының күчмә турында катнашучылар булып, әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында билгеләнгән һәр яшь категориясе буенча, оештыру комитеты билгеләгән квота нигезендә, читтән торып тур нәтиҗәләре буенча җыйган

баллар нәтиҗәсендә рейтинг исемлегендә урын алучы читтән торып тур катнашучылары тора.

8.5. Күчмә турда катнашучыларның чыгышлары Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә чыгып, Жюри тарафыннан бәяләнә.

8.6. Күчмә турны үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә 2026 елның 15 апреленә кадәр бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша җиткерелә.

8.7. Фестивальнең күчмә турында катнашучыларның һәрберсенә Фестивальнең республика этабында катнашучы сертификаты тапшырыла.

## IX. Фестиваль катнашучыларының чыгышларына таләпләр

9.1. Фестиваль катнашучылары туган телләрдә (татар, чуваш, удмурт, мари, мордва) спектакльдән өзек тәкъдим итәләр.

9.2. Чыгыш вакыты – 10 минутка кадәр.

9.3. Чыгышларны бәяләү критерийлары:

| Чыгыш | | |
|---|---|---|
| 1 | Әсәр темасын тулы һәм тәэсирле ачу; образны сөйләм аша ачу: тавыш көче, дикция, эмоциональлек; сәнгати-образлы фикерләүнең тирәнлеге, ышандыру көче; спектакльнең визуаль-гамәли рәтенең бөтенлеге | туры килә – 2 балл<br>туры килми- 0 балл |
| 2 | Актерның тышкы тәэсирле чаралары (артистлык): пластика, ишарәләр, мимика, костюмнарның булуы һәм аларның спектакльгә туры килүе, башкару культурасы | туры килә – 2 балл<br>туры килми- 0 балл |
| 3 | Спектакльнең сәнгати бизәлеше:<br>декорация, музыка, яктылык, реквизит | туры килә – 2 балл<br>туры килми- 0 балл |
| 4 | Репертуарның башкаручыларның яшь үзенчәлекләренә туры килүе, сәхнә материалының режиссер тәкъдиме, спектакль куюда иҗади фикерләр яңалыгы | туры килә – 2 балл<br>туры килми- 0 балл |
| | | Баллар суммалаштырыла. Максималь балл саны – 8 |

## X. Фестивальнең нәтиҗәләрен чыгару

10.1. Күчмә тур нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән катнашучыларның һәр категориясе буенча катнашучыларның рейтинг исемлеге формалаштырыла, анда әлеге категорияне бәяләүдә катнашкан һәр экспертның баллары кертелә.

10.2. Күчмә тур йомгаклары буенча Гран-при иясе, I, II, III дәрәҗә җиңүчеләр һәм Фестиваль лауреатлары билгеләнә.

10.3. «Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбияләнүчеләре» категориясендә Гран-при иясе булып әлеге категория буенча күчмә этапта катнашучылар рейтинг исемлегендә беренче урынны алган катнашучы тора.

Гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасыннан Гран-при иясе булып «гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучылары», «гомуми белем бирү оешмаларының 5-8 сыйныф укучылары», «гомуми белем бирү оешмаларының 9-11 сыйныф укучылары» категорияләре арасыннан, күчмә турның рейтинг исемлекләрендә беренче позицияләрне алып торучы катнашучылар арасыннан, эффективлык коэффициенты иң зур булган бер катнашучы санала.

Эффективлык коэффициенты (ЭК) түбәндәгечә билгеләнә:

ЭК = Бфакт/Бмакс х 100%, биредә: ЭК – эффективлык коэффициенты; Бфакт – Фестивальнең күчмә туры катнашучысы фактта җыйган баллар; Бмакс – әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән катнашучы категориясе өчен каралган Фестивальнең күчмә туры өчен максималь мөмкин булган баллар. Әгәр рейтинг исемлегендә беренче позицияне алып торучы ике яки өч Фестиваль катнашучысының эффективлык коэффициенты бер үк булса, Гран-при иясен билгеләү буенча карар Жюри утырышында жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Жюри утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

10.4. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары төркемнәре категориясендә I дәрәҗәдәге җиңүче булып әлеге категория буенча күчмә этапта катнашучылар рейтинг исемлегендә икенче урынны алган катнашучы була. Гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасыннан I дәрәҗәдәге җиңүчеләр булып әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән һәр яшь категориясе буенча рейтинг исемлекләрендә беренче урыннарны алып торучы катнашучылар була. Әгәр рейтинг исемлегендә беренче позицияне алып торучы Фестиваль катнашучысының балл саны рейтинг исемлегендә аның артыннан килүчеләрдәге белән тигез булса, бу катнашучылар буенча карар Жюри утырышында жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Беренче позицияне алып торучы катнашучы Гран-при иясе дип танылган категориядә I дәрәҗәдәге җиңүче булып рейтинг исемлегендә икенче позицияне алып торучы катнашучы була.

10.5. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары төркемнәре категориясендә II дәрәҗәдәге җиңүче булып әлеге категория буенча күчмә этапта катнашучылар рейтинг исемлегендә өченче урынны алган катнашучы була. Гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасыннан II дәрәҗәдәге җиңүчеләр булып һәр яшь категориясе буенча рейтинг исемлекләрендә икенче урыннарны алып торучы катнашучылар була. Әгәр рейтинг исемлегендә икенче позицияне алып торучы Фестиваль катнашучысының балл саны рейтинг исемлегендә аның артыннан килүчеләрдәге белән тигез булса, бу катнашучылар буенча карар Жюри утырышында жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Жюри утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Беренче позицияне алып торучы катнашучы Гран-при иясе дип танылган категориядә II дәрәҗәдәге җиңүче булып рейтинг исемлегендә өченче позицияне алып торучы катнашучы була.

10.6. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары төркемнәре категориясендә III дәрәҗәдәге җиңүче булып әлеге категория буенча күчмә этапта катнашучылар рейтинг исемлегендә дүртенче урынны алган катнашучы була. Гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасыннан III дәрәҗәдәге җиңүчеләр булып һәр яшь категориясе буенча рейтинг исемлекләрендә өченче урыннарны алып торучы катнашучылар була. Әгәр рейтинг исемлегендә өченче позицияне алып торучы Фестиваль катнашучысының балл саны рейтинг исемлегендә аның артыннан килүчеләрдәге белән тигез булса, бу катнашучылар буенча карар Жюри утырышында жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Жюри утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Беренче позицияне алып торучы катнашучы Гран-при иясе дип танылган категориядә III дәрәҗәдәге җиңүче булып рейтинг исемлегендә дүртенче позицияне алып торучы катнашучы була.

10.7. Лауреатлар булып рейтинг исемлекләрендә III дәрәҗә җиңүчеләреннән соң урыннар алып торучы катнашучылар таныла. Лауреатлар квотасы Оргкомитет тарафыннан билгеләнә. Лауреатлар буенча карар Жюри утырышында кабул ителә.

10.8. Фестивальнең күчмә этабы беркетмәсе, рейтинг исемлеге теркәлеп һәм Гран-при ияләре, җиңүчеләр һәм лауреатлар күрсәтелеп, Жюри рәисе тарафыннан имзалана. Гран-при ияләре, җиңүчеләр һәм лауреатлар исемлеге Министрлык боерыгы белән раслана һәм расланганнан соң җиде эш көне эчендә Министрлык сайтында урнаштырыла.

10.9. Гран-при ияләре, җиңүчеләр һәм лауреатлар Министрлык дипломнары һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

10.10. Фестиваль җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы Казан шәһәрендә үтә. Тантананы үткәрү урыны һәм датасы Фестиваль Оргкомитеты тарафыннан билгеләнә һәм катнашучыларга бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша рәсми хат белән хәбәр ителә.

10.11. Фестиваль нәтиҗәләре турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында (https://mon.tatarstan.ru/ ) урнаштырыла.

## XI. Элемтә өчен мәгълүматы

11.1. Оештыру комитетының адресы: Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 нчы йорт, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Телефон 8(843) 222-78-56 (Закирҗанова Зөлфия Тәлгать кызы).

## XII. Фестивальне финанслау

12.1. Фестивальне финанслау Дәүләт программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

2025/2026 уку елында «Сәйяр»
балалар һәм яшүсмерләр театрлары
республика фестивален үткәрү
турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта
ФОРМА

2025/2026 уку елында «Сәйяр» балалар һәм яшүсмерләр театрлары республика фестивалендә катнашу өчен
ГАРИЗА

| Татарстан Республикасы муниципаль районы исеме | № т/б | Муниципаль этап җиңүчесе (белем бирү оешмасының устав буенча исеме) | Куелыш катнашучылары саны | Куелыш теле (татар, чуваш, удмурт, мари, мордва) | Видеоязмага керү өчен сылтама, автор (Ф.И.А.) һәм әсәр исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| | Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары төркемнәре | | | | |
| | 1 нче Катнашучы | | | | |
| | 2 нче Катнашучы | | | | |
| | 3 нче Катнашучы | | | | |
| | 1 – 4 сыйныфлар | | | | |
| | 1 нче Катнашучы | | | | |
| | 2 нче Катнашучы | | | | |
| | 3 нче Катнашучы | | | | |
| | 5 – 8 сыйныфлар | | | | |
| | 1 нче Катнашучы | | | | |
| | 2 нче Катнашучы | | | | |
| | 3 нче Катнашучы | | | | |
| | 9 – 11 сыйныфлар | | | | |
| | 1 нче Катнашучы | | | | |
| | 2 нче Катнашучы | | | | |
| | 3 нче Катнашучы | | | | |

Расланды
Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгының 2025
елның «__» _____ _____ ___
номерлы боерыгы белән

2025/2026 уку елында «Сәйяр» балалар һәм үсмерләр театрлары республика фестивален үткәрү буенча оештыру комитеты составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Закирова Минзәлия Заһри кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе |
| 2. | Шәрипова Алсу Сәмигулла кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының (алга таба – Министрлык) милли мәгариф идарәсе башлыгы |
| 3. | Гыйзәтуллина Энҗе Хәбир кызы | Министрлыкның милли мәгариф бүлеге башлыгы |
| 4. | Хисамиева Йолдыз Шамил кызы | Министрлыкның мәктәпкәчә белем бирү бүлеге башлыгы |
| 5. | Закирҗанова Зөлфия Тәлгать кызы | Министрлыкның милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы консультанты, оештыру комитеты сәркатибе |
| 6. | Галявеева Чулпан Хәйдәр кызы | Министрлыкның мәктәпкәчә белем бирү бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе |